Республика Татарстан Петровско-Заводское сельское поселение Сармановского муниципального района	Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Петровский Завод авыл җирлеге

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.11.2020 г. № 9

Петровский Завод авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 20 мартындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Петровский Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Петровский Завод авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Петровский Завод авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 20 мартындагы 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан салым аванс белән, узган хисап чорыннан агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң, җир кишәрлегенең кадастр бәясе процентының тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә түләнә. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча түләнә».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.«Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылган көннән бер айдан да иртәрәк түгел».

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Петровский Завод авыл җирлеге
Советы Рәисе А.Б.Хөснетдинов